РЕШЕНИЕ КАРАР
28.11.2018г. ______

Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 28 апрелендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү, аларның хезмәте өчен түләүне камилләштерү һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында"гы карары, Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 28 апрелендәге 6 номерлы карарына, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Әлеге карар upecy:http://pravo.tatarstan.ru № i буенча Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталы»нда һәм Кәзкәй авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.Хөрмәев